**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** | **КАРАР**

**16.05. 2022 ел** | **№ 168**

## 2022 елда төзекләндерү буенча муниципаль конкурслар үткәрү турында

Муниципаль берәмлекләрнең төзеклеген арттыру мәсьәләләрендә муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары активлыгын арттыру, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының уңай тәҗрибәсен өйрәнү һәм тарату максатларында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда «Биектау муниципаль районының иң яхшы йорт-җире» исеменә муниципаль конкурс игълан итәргә һәм үткәрергә.
2. 2022 елда «Биектау муниципаль районының иң яхшы йорт-җире» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
3. 2022 елда «Биектау муниципаль районының (Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләреннән тыш) иң яхшы авыл җирлеге» исеменә муниципаль конкурс игълан итәргә һәм үткәрергә.
4. 2022 елда «Биектау муниципаль районының иң яхшы авыл җирлеге (Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләреннән тыш)» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга (2 нче кушымта).
5. 2022 елда «Биектау муниципаль районы авыл җирлегендә (Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләреннән тыш) иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс игълан итәргә һәм үткәрергә.
6. 2022 елда «Биектау муниципаль районы авыл җирлегендә (Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләреннән тыш) иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга (3 нче кушымта).
7. 2022 елда «Биектау муниципаль районының район үзәгендә иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс игълан итәргә һәм үткәрергә.
8. 2022 елда «Биектау муниципаль районының район үзәгендә иң яхшы

күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга (4 нче кушымта).

9. 2022 елда «Биектау муниципаль районының иң яхшы бюджет оешмасы» исеменә муниципаль конкурс игълан итәргә һәм үткәрергә.

10. 2022 елда «Биектау муниципаль районының иң яхшы бюджет оешмасы» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга (5 нче кушымта).

11. 2022 елда «Биектау муниципаль районы авыл җирлегендә (Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләреннән тыш) иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс игълан итәргә һәм үткәрергә.

12. 2022 елда «Биектау муниципаль районы авыл җирлегендә (Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләреннән тыш) иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга (6 нчы кушымта).

13. Төзекләндерү буенча муниципаль конкурслар үткәрүнең конкурс комиссиясе составын расларга (7 нче кушымта).

14. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе урынбасары,
муниципаль район Башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакиров

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2022 елның 16 маендагы 168
номерлы карары белән расланды

**«Биектау муниипаль районының 2022 елда «Биектау муниципаль районының иң яхшы йорт-җире» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмә**

1. «Биектау муниципаль районының иң яхшы йорт-җире» исеменә муниципаль конкурс (алга таба текст буенча - конкурс) конкурс үткәрү максаты булып йорт яны территорияләрен төзекләндерү һәм чисталык дәрәҗәсен, торак йортларның һәм хуҗалык корылмаларының эстетик йөзе, шулай ук шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару культурасы дәрәҗәсен күтәрү тора. Конкурсның бурычлары - йорт яны участокларын һәм торак йортларны карап тоту буенча культура дәрәҗәсен һәм үрнәк тәртипне арттыру, Биектау муниципаль районы авыл җирлекләрендә йорт хайваннарын тоту өчен кирәкле санитар шартлар тудыру, социаль актив гаиләләрне ачыклау һәм бүләкләү.

2. Конкурсны үткәрү вакыты: 2022 елның 15 июленнән 2022 елның 15 августына кадәр.

3. Конкурс үткәргәндә йорт-җирнең төзеклеге түбәндәге юнәлешләр буенча исәпкә алына:

йорт-җирнең архитектур йөзе һәм төзеклеге;

ишегалды территориясе, торак йортның оригиналь бизәлеше, анда чисталык һәм уңайлылык;

торак йорт, йорт-җир бизәлешендә милли гореф-гадәтләр куллану;

яшелләндерү;

йорт-җирне бизәүдә  креатив идеяләр куллану;

ярдәмче хуҗалык булу һәм алып бару;

торак пунктның, авыл җирлегенең иҗтимагый һәм мәдәни тормышында актив катнашу;

сәламәт яшәү рәвеше алып бару, актив ял итү формалары куллану,

гаилә мавыгулары булу, гаиләдә балаларның тулы канлы үсеше өчен шартлар тудыру (спорт мәйданчыклары, балалар бүлмәләре);

җәмәгать урыннарында һәм көнкүрештә үз-үзеңне тоту культурасы;

эш урыны буенча хезмәт дисциплинасын үтәү;

йорт терлекчелеген алып бару сыйфаты;

ял урыннары булу һәм аларның торышы;

(Бәяләү бите кушымта итеп бирелә).

4. Конкурста Биектау муниципаль районының барлык хуҗалыклары да катнаша.

5. Конкурс үткәрү һәм аңа йомгак ясау максатыннан район Башлыгы урынбасары карары белән конкурс комиссиясе төзелә.

Конкурс комиссиясе составы районның җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары, җәмәгатьчелек вәкилләреннән төзелә.

6. Комиссиянең төп функцияләре булып тора:

а) шәхси хуҗалыклар территорияләрен тикшерү;

б) конкурс комиссиясе утырышын оештыру;

в) конкурска йомгак ясау;

г) конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыру;

д) массакүләм мәгълүмат чараларында конкурсны һәм аның нәтиҗәләрен яктыртуны оештыру.

7. Конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс нәтиҗәләре 2022 ел августының өченче декадасында ясала.

8. Конкурс нәтиҗәләре буенча өч призер билгеләнә.

9. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының өчтән икесеннән ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Карар һәр претендент буенча ачык тавыш бирү юлы белән, баллар суммасы буенча гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

10. Конкурс комиссиясе утырышы барышы һәм җиңүчеләрне билгеләү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә.

11. Конкурста призлы урыннар алган хуҗалыклар түбәндәге суммага сертификатлар белән бүләкләнәләр

1 нче урын - 100 мең сум;

2 нче урын – 75 мең сум;

3 нче урын – 50 мең сум.

12. Сертификат призлы урын алган территорияне төзекләндерү буенча чараларны башкаруга кулланыла.

13. Максатчан акчаларны тоту турында хисапны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә 2023 елның 1 сентябренә кадәр тапшырырга кирәк (төзекләндерү буенча чаралар үткәрелгәнгә кадәр һәм аннан соң фотоматериал беркетеп).

2022 елда «Биектау муниципаль районының иң яхшы йорт-җире» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмәгә кушымта

**Бәяләү кәгазе**
**(10 баллы шкала буенча)**
**_______________ йорт хуҗалыгы**

| № | Критерийлар | Бәя |
|---|---|---|
| **1** | йорт-җирнең архитектур йөзе һәм төзеклеге | |
| **2** | ишегалды территориясе, торак йортның оригиналь бизәлеше, анда чисталык һәм уңайлылык | |
| **3** | торак йорт, йорт-җир бизәлешендә милли гореф-гадәтләр куллану | |
| **4** | яшелләндерү | |
| **5** | йорт-җирне бизәүдә  креатив идеяләр куллану | |
| **6** | торак пунктның, авыл җирлегенең иҗтимагый һәм мәдәни тормышында актив катнашу | |
| **7** | сәламәт яшәү рәвеше алып бару, актив ял итү формалары куллану | |
| **8** | гаилә мавыгулары булу, гаиләдә балаларның тулы канлы үсеше өчен шартлар тудыру (спорт мәйданчыклары, балалар бүлмәләре) | |
| **9** | җәмәгать урыннарында һәм көнкүрештә үз-үзеңне тоту культурасы | |
| **10** | эш урыны буенча хезмәт дисциплинасын үтәү | |
| **11** | йорт терлекчелеген алып бару сыйфаты | |
| **12** | ял урыннары булу һәм аларның торышы | |
| | **Барлыгы** | |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2022 елның 16 маендагы 168
номерлы карары белән расланды

**2022 елда «Биектау муниципаль районының иң яхшы авыл җирлеге (Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләреннән тыш)» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмә**

1. «Биектау муниципаль районының иң яхшы авыл җирлеге (Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләреннән тыш)» исеменә муниципаль конкурсы (алга таба текст буенча - конкурс) муниципаль берәмлекләрнең төзеклеген арттыру мәсьәләләрендә муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары активлыгын арттыру, Биектау муниципаль районында муниципаль берәмлекләр җирле үзидарә органнарының уңай тәҗрибәсен өйрәнү һәм тарату максатларында максатларында үткәрелә.

2. Конкурсны үткәрү вакыты: 2022 елның 15 июленнән 2022 елның 15 августына кадәр.

3.Конкурс үткәргәндә түбәндәгеләр исәпкә алына:

ташландык йорт хуҗалыклары булу/булмау, аларның йорт яны территорияләренең торышы;

санитар чистарту һәм территорияне төзекләндерү;

авыл җирлеге территориясендә биналарның архитектур йөзе һәм төзеклеге;

санкцияләнмәгән чүплекләр булмау;

ишегалды территориясен яшелләндерү, чәчәк түтәлләре, газоннар булу,

куаклар һәм агачларны вакытында кыскартып кисү;

территорияне бизәүдә креатив идеяләрне куллану;

җирләү урыннарын төзекләндерү;

халыкны төзекләндерү буенча җәмәгать эшләренә җәлеп итү;

урамнарны яктырту торышы;

юл-урам челтәре торышы;

урам күрсәткечләренең, тышкы визуаль мәгълүмат чараларының (географик объектларның, елгаларның, сулыкларның, аншлагларның исемнәре) торышы;

сулыклар, чишмәләр территорияләрен төзекләндерү;

ял урыннарының булуы һәм торышы;

социаль әһәмияттәге объектлар территорияләрен төзекләндерү.

(Бәяләү бите кушымта итеп бирелә).

4. Авыл җирлекләренең төзеклеген һәм чисталыгын бәяләү район Башлыгы урынбасары карары белән оештырылган конкурс комиссиясе тарафыннан башкарыла.

5. Конкурс комиссиясе составы районның җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары, җәмәгатьчелек вәкилләреннән төзелә.

6. Комиссиянең төп функцияләре булып тора:

а) авыл җирлекләре территорияләрен тикшерү;

б) конкурс комиссиясе утырышын оештыру;

в) конкурска йомгак ясау;

г) конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыру;

д) массакүләм мәгълүмат чараларында конкурсны һәм аның нәтиҗәләрен яктыртуны оештыру.

7. Конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс нәтиҗәләре 2022 ел августының өченче декадасында ясала.

8. Конкурс нәтиҗәләре буенча өч призер билгеләнә.

9. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының өчтән икесеннән ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Карар һәр претендент буенча ачык тавыш бирү юлы белән, баллар суммасы буенча гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

10. Конкурс комиссиясе утырышы барышы һәм җиңүчеләрне билгеләү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә.

11. Акчалата премияләр

1 нче урын - 500 мең сум;

2 нче урын – 300 мең сум;

3 нче урын – 250 мең сум.

12. Акчалата премия авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан үз җирлеге территориясендә төзекләндерү, яшелләндерү, балалар һәм спорт мәйданчыклары урнаштыру, төзекләндерү чараларын үтәү өчен техника сатып алуга тотыла.

13. Максатчан акчаларны тоту турында хисапны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә 2023 елның 1 сентябренә кадәр 8 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча тапшырырга кирәк (төзекләндерү буенча чаралар үткәрелгәнгә кадәр һәм аннан соң фотоматериал беркетеп).

«Биектау муниципаль районының иң яхшы авыл җирлеге (Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләреннән тыш)» исеменә муниципаль конкурсы турында нигезләмәгә кушымта

**Бәяләү кәгазе**
**__________________ авыл җирлеге**

**(10 баллы шкала буенча)**

| **№** | **Бәяләү критерийлары** | **Баллар** |
|---|---|---|
| **1** | ташландык йорт хуҗалыклары булу/булмау, аларның йорт яны территорияләренең торышы | |
| **2** | санитар чистарту һәм территорияне төзекләндерү | |
| **3** | авыл җирлеге территориясендә биналарның архитектур йөзе һәм төзеклеге | |
| **4** | санкцияләнмәгән чүплекләр булмау | |
| **5** | ишегалды территориясен яшелләндерү, чәчәк түтәлләре, газоннар булу,<br>куаклар һәм агачларны вакытында кыскартып кисү | |
| **6** | җирләү урыннарын төзекләндерү | |
| **7** | урамнарны яктырту торышы | |
| **8** | юл-урам челтәре торышы | |
| **9** | урам күрсәткечләренең, тышкы визуаль мәгълүмат чараларының (географик объектларның, елгаларның, сулыкларның, аншлагларның исемнәре) торышы | |
| **10** | сулыклар, чишмәләр территорияләрен төзекләндерү | |
| **11** | ял урыннарының булуы һәм торышы | |
| **12** | социаль әһәмияттәге объектлар территорияләрен төзекләндерү | |
| | **БАРЛЫГЫ:** | |

3 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2022 елның 16 маендагы 168
номерлы карары белән расланды

**2022 елда «Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегендә иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмә**

1. «Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегендә иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс (алга таба-конкурс) Биектау муниципаль районында күпфатирлы йортларның төзеклеген арттыру мәсьәләләрендә гражданнарның, торак милекчеләре ширкәтләренең, идарәче компанияләрнең активлыгын арттыру максатыннан үткәрелә.

2. Конкурсны үткәрү вакыты: 2022 елның 15 июленнән 2022 елның 15 августына кадәр.

3. Конкурсны үткәргәндә күп фатирлы йортларның төзеклеге һәм чисталыгы исәпкә алына (бәяләү кәгазе кушып бирелә).

4. Урамнарның төзеклеген һәм чисталыгын бәяләү район башлыгы урынбасары тарафыннан оештырылган конкурс комиссиясе тарафыннан башкарыла.

5. Конкурс комиссиясе составы районның җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары, җәмәгатьчелек вәкилләреннән төзелә.

6. Комиссиянең төп функцияләре булып тора:

а) территорияләрне тикшерү;

б) конкурс комиссиясе утырышын оештыру;

в) конкурска йомгак ясау;

г) конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыру;

д) массакүләм мәгълүмат чараларында конкурсны һәм аның нәтиҗәләрен яктыртуны оештыру.

7. Конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс нәтиҗәләре 2022 ел августының өченче декадасында ясала.

8. Конкурс нәтиҗәләре буенча өч призер билгеләнә.

9. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының өчтән икесеннән ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Карар һәр претендент буенча ачык тавыш бирү юлы белән, баллар суммасы буенча гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

10. Конкурс комиссиясе утырышы барышы һәм җиңүчеләрне билгеләү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә.

11. Акчалата премияләр

1 нче урын - 200 мең сум;

2 нче урын – 150 мең сум;

3 нче урын – 100 мең сум.

12. Акчалата премия торак милекчеләре ширкәте, идарәче компания тарафыннан призер күпфатирлы йорт территориясендә төзекләндерү, яшелләндерү, балалар һәм спорт мәйданчыклары урнаштыру өчен тотыла.

13. Максатчан акчаларны тоту турында хисапны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә 2023 елның 1 сентябренә кадәр 8 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча тапшырырга кирәк (төзекләндерү буенча чаралар үткәрелгәнгә кадәр һәм аннан соң фотоматериал беркетеп).

2022 елда «Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегендә иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмәгә кушымта

**Бәяләү кәгазе**

**_______________________ күпфатирлы йорт**

**(10 баллы шкала буенча)**

| **№** | **Бәяләү критерийлары** | **Баллар** |
|---|---|---|
| **1** | Күпфатирлы йорт фасадының тышкы күренеше | |
| **2** | Күп фатирлы йорт территориясен санитар җыештыру | |
| **3** | Төзелеш материаллары, утын, иске кулланылмый торган техника, йөк автомобильләре һ. б. булмау. | |
| **5** | Өй яны бакчаларын һәм участокка якын-тирә территорияләрне яшелләндерү | |
| **6** | Өлкәннәр, яшьләр һәм балалар өчен ял итү урыннары булу һәм аларның торышы | |
| **7** | Ике дәүләт телендә урам исеме һәм йорт номеры күрсәткеченең булуы | |
| **8** | Йорт яны территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү, чисталык һәм тәртиптә тоту, кече архитектура формаларын ремонтлау һәм саклау, өмәләр үткәрү, ишегалдын эстетик бизәүдә иҗади инициатива күрсәтүдә халыкның катнашуы, шул исәптән чәчәк түтәлләре булу. | |
| **9** | Кече архитектура формаларын карап тоту (эскәмияләр, балалар һәм спорт мәйданчыклары, чүп савытлары, кием киптерү, келәмнәр кагу өчен җайланмалар булу һәм аларның торышы) | |
| **10** | Контейнер мәйданчыгын карап тоту (тышкы кыяфәте һәм санитар торышы) | |
| **11** | Мәҗбүри мәгълүмат урнаштырылган белдерү тактасы (такталары), күрсәткечләр булу | |
| **12** | Ишегалды территориясенең яктыртылышы | |
| | **БАРЛЫГЫ:** | |

4 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2022 елның 16 маендагы 168
номерлы карары белән расланды

**2022 елда «Биектау муниципаль районының район үзәгендә иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмә**

1. **«Биектау муниципаль районының район үзәгендә иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс** (алга таба текст буенча - конкурс) Биектау муниципаль районында күпфатирлы йортларның ишегаллары төзеклеген арттыру мәсьәләләрендә гражданнарның, торак милекчеләре ширкәтләренең, идарәче компанияләрнең активлыгын арттыру максатыннан үткәрелә.

2. Конкурсны үткәрү вакыты: 2022 елның 15 июленнән 2022 елның 15 августына кадәр.

3. Конкурсны үткәргәндә Биектау муниципаль районы район үзәгендә күпфатирлы йортның төзеклеге һәм чисталыгы торышы исәпкә алына (бәяләү кәгазе кушып бирелә).

4. Йорт биләмәләренең төзеклеген һәм чисталыгын бәяләү бәяләү район Башлыгы урынбасары карары белән оештырылган конкурс комиссиясе тарафыннан күпфатирлы йорт милекчеләре ризалыгы белән башкарыла.

5. Конкурс комиссиясе составы районның җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары, җәмәгатьчелек вәкилләреннән төзелә.

6. Комиссиянең төп функцияләре булып тора:

а) күпфатирлы йортның иң төзеген ачыклау максатыннан торак пунктлар территорияләрен тикшерү;

б) конкурс комиссиясе утырышын оештыру;

в) конкурска йомгак ясау;

г) конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыру;

д) массакүләм мәгълүмат чараларында конкурсны һәм аның нәтиҗәләрен яктыртуны оештыру.

7. Конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс нәтиҗәләре 2022 ел августының өченче декадасында ясала.

8. Конкурс нәтиҗәләре буенча җиңүчеләр билгеләнә.

9. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының өчтән икесеннән ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Карар һәр претендент буенча ачык тавыш бирү юлы белән, баллар суммасы буенча гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

10. Конкурс комиссиясе утырышы барышы һәм җиңүчеләрне билгеләү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә.

11. Акчалата премияләр

1 нче урын - 200 мең сум;

2 нче урын – 150 мең сум;

3 нче урын – 100 мең сум.

12. Акчалата премия торак милекчеләре ширкәте, идарәче компания тарафыннан призер күпфатирлы йорт территориясендә төзекләндерү, яшелләндерү, балалар һәм спорт мәйданчыклары урнаштыру өчен тотыла.

13. Максатчан акчаларны тоту турында хисапны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә 2023 елның 1 сентябренә кадәр 8 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча тапшырырга кирәк (төзекләндерү буенча чаралар үткәрелгәнгә кадәр һәм аннан соң фотоматериал беркетеп).

2022 елда «Биектау муниципаль районының район үзәгендә иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмәгә кушымта

**Бәяләү кәгазе**
**(10 баллы шкала буенча)**

Адресы: ___________________________________________________________

**(10 баллы шкала буенча)**

| **№** | **Бәяләү критерийлары** | **Баллар** |
|---|---|---|
| **1** | Күпфатирлы йорт фасадының тышкы күренеше | |
| **2** | Күп фатирлы йорт территориясен санитар җыештыру | |
| **3** | Төзелеш материаллары, утын, иске кулланылмый торган техника, йөк автомобильләре һ. б. булмау. | |
| **4** | Өй яны бакчаларын һәм участокка якын-тирә территорияләрне яшелләндерү | |
| **5** | Өлкәннәр, яшьләр һәм балалар өчен ял итү урыннары булу һәм аларның торышы | |
| **6** | Ике дәүләт телендә урам исеме һәм йорт номеры күрсәткеченең булуы | |
| **7** | Йорт яны территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү, чисталык һәм тәртиптә тоту, кече архитектура формаларын ремонтлау һәм саклау, өмәләр үткәрү, ишегалдын эстетик бизәүдә иҗади инициатива күрсәтүдә халыкның катнашуы, шул исәптән чәчәк түтәлләре булу | |
| **8** | Кече архитектура формаларын карап тоту (эскәмияләр, балалар һәм спорт мәйданчыклары, чүп савытлары, кием киптерү, келәмнәр кагу өчен җайланмалар булу һәм аларның торышы) | |
| **9** | Контейнер мәйданчыгын карап тоту (тышкы кыяфәте һәм санитар торышы) | |
| **10** | Мәҗбүри мәгълүмат урнаштырылган белдерү тактасы (такталары), күрсәткечләр булу | |
| **11** | Ишегалды территориясенең яктыртылышы | |
| | **БАРЛЫГЫ:** | |

5 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2022 елның 16 маендагы 168
номерлы карары белән расланды

**2022 елда «Биектау муниципаль районының иң яхшы бюджет оешмасы» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмә**

1. **«Биектау муниципаль районының иң яхшы бюджет оешмасы» исеменә муниципаль конкурс** (алга таба текст буенча - конкурс) Биектау муниципаль районы бюджет оешмаларының төзеклеген арттыру, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының уңай тәҗрибәсен өйрәнү һәм тарату мәсьәләләрендә активлыгын арттыру максатыннан үткәрелә

2. Конкурсны үткәрү вакыты: 2022 елның 15 июленнән 2022 елның 15 августына кадәр.

3. Конкурс үткәргәндә Биектау муниципаль районында бюджет оешмаларының төзеклеге һәм чисталыгы исәпкә алына (бәяләү бите кушып бирелә).

4. Бюджет оешмаларының төзеклеген һәм чисталыгын бәяләү район башлыгы урынбасары карары белән төзелгән конкурс комиссиясе тарафыннан бюджет оешмалары ризалыгы белән башкарыла.

5. Конкурс комиссиясе составы районның җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары, җәмәгатьчелек вәкилләреннән төзелә.

6. Комиссиянең төп функцияләре булып тора:

а) территорияләрне иң төзек оешманы билгеләү максатыннан карап тикшерү;

б) конкурс комиссиясе утырышын оештыру;

в) конкурска йомгак ясау;

г) конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыру;

д) массакүләм мәгълүмат чараларында конкурсны һәм аның нәтиҗәләрен яктыртуны оештыру.

7. Конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс нәтиҗәләре 2022 ел августының өченче декадасында ясала.

8. Конкурс нәтиҗәләре буенча җиңүчеләр билгеләнә.

9. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының өчтән икесеннән ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Карар һәр претендент буенча ачык тавыш бирү юлы белән, баллар суммасы буенча гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

10. Конкурс комиссиясе утырышы барышы һәм җиңүчеләрне билгеләү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә.

11. Акчалата премияләр

1 нче урын - 200 мең сум;

2 нче урын – 150 мең сум;

3 нче урын – 100 мең сум.

12. Акчалата премия призер бюджет оешмасы территориясендә төзекләндерү, яшелләндерү чараларын үтәүгә бюджет оешмасы тарафыннан тотыла.

13. Максатчан акчаларны тоту турында хисапны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә 2023 елның 1 сентябренә кадәр 8 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча тапшырырга кирәк (төзекләндерү буенча чаралар үткәрелгәнгә кадәр һәм аннан соң фотоматериал беркетеп).

2022 елда «Биектау муниципаль районының иң яхшы бюджет оешмасы» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмәгә кушымта

**Бәяләү кәгазе**
**(10 баллы шкала буенча)**

______________________________________________________________
бюджет оешмасы

**(10 баллы шкала буенча)**

| **№** | **Бәяләү критерийлары** | **Баллар** |
|---|---|---|
| **1** | Бюджет оешмасы фасадының тышкы кыяфәте | |
| **2** | Территорияне санитар җыештыру | |
| **3** | Халыкның аз мобиль төркемнәре өчен бинадан файдалану мөмкинлеге | |
| **4** | Гомуми яшелләндерү | |
| **5** | Ике дәүләт телендә оешма, урам исеме һәм йорт номеры күрсәткеченең булуы | |
| **6** | Чүп савытлары (тышкы кыяфәте һәм санитар торышы) | |
| **7** | Ике дәүләт телендә оешма исеме булуы | |
| **8** | Территориянең яктыртылышы | |
| **9** | Янгынга каршы кагыйдәләр үтәлеше | |
| **10** | Террорчылыкка каршы якланган булуы, видеокүзәтү камералары булу | |
| **11** | Бюджет оешмасына килүчеләр өчен парковка урыннары булу | |
| | **БАРЛЫГЫ:** | |

6 нчы кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2022 елның 16 маендагы 168
номерлы карары белән расланды

**2022 елда «Биектау муниципаль районы авыл җирлегендә (Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләреннән тыш) иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмә**

1. «Биектау муниципаль районы авыл җирлегендә (Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләреннән тыш) иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс (алга таба текст буенча - конкурс) Биектау муниципаль районында күпфатирлы йортлар ишегалларының төзеклеген арттыру мәсьәләләрендә гражданнарның, торак милекчеләре ширкәтләренең, идарәче компанияләрнең активлыгын арттыру максатыннан үткәрелә.

2. Конкурсны үткәрү вакыты: 2022 елның 15 июленнән 2022 елның 15 августына кадәр.

3. Конкурсны үткәргәндә күп фатирлы йортларның төзеклеге һәм чисталыгы исәпкә алына (бәяләү кәгазе кушып бирелә).

4. Урамнарның төзеклеген һәм чисталыгын бәяләү район Башлыгы урынбасары карары белән оештырылган конкурс комиссиясе тарафыннан башкарыла.

5. Конкурс комиссиясе составы районның җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары, җәмәгатьчелек вәкилләреннән төзелә.

6. Комиссиянең төп функцияләре булып тора:

а) территорияләрне тикшерү;

б) конкурс комиссиясе утырышын оештыру;

в) конкурска йомгак ясау;

г) конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыру;

д) массакүләм мәгълүмат чараларында конкурсны һәм аның нәтиҗәләрен яктыртуны оештыру.

7. Конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс нәтиҗәләре 2022 ел августының өченче декадасында ясала.

8. Конкурс нәтиҗәләре буенча өч призер билгеләнә.

9. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының өчтән икесеннән ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала. Карар һәр претендент буенча ачык тавыш бирү юлы белән, баллар суммасы буенча гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

10. Конкурс комиссиясе утырышы барышы һәм җиңүчеләрне билгеләү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә.

11. Акчалата премияләр

1 нче урын - 200 мең сум;

2 нче урын – 150 мең сум;

3 нче урын – 100 мең сум.

12. Акчалата премия торак милекчеләре ширкәте, идарәче компания тарафыннан призер күпфатирлы йорт территориясендә төзекләндерү, яшелләндерү, балалар һәм спорт мәйданчыклары урнаштыру өчен тотыла.

13. Максатчан акчаларны тоту турында хисапны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә 2023 елның 1 сентябренә кадәр 8 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча тапшырырга кирәк (төзекләндерү буенча чаралар үткәрелгәнгә кадәр һәм аннан соң фотоматериал беркетеп).

2022 елда «Биектау муниципаль районы авыл җирлегендә (Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләреннән тыш) иң яхшы күпфатирлы йорт» исеменә муниципаль конкурс турында нигезләмәгә кушымта

**Бәяләү кәгазе**
**күпфатирлы йорт______________________**

**(10 баллы шкала буенча)**

| **№** | **Бәяләү критерийлары** | **Баллар** |
|---|---|---|
| **1** | Күпфатирлы йорт фасадының тышкы күренеше | |
| **2** | Күпфатирлы йорт территориясен санитар җыештыру | |
| **3** | Төзелеш материаллары, утын, иске кулланылмый торган техника, йөк автомобильләре һ. б. булмау. | |
| **5** | Өй яны бакчаларын һәм участокка якын-тирә территорияләрне яшелләндерү | |
| **6** | Өлкәннәр, яшьләр һәм балалар өчен ял итү урыннары булу һәм аларның торышы | |
| **7** | Ике дәүләт телендә урам исеме һәм йорт номеры күрсәткеченең булуы | |
| **8** | Йорт яны территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү, чисталык һәм тәртиптә тоту, кече архитектура формаларын ремонтлау һәм саклау, өмәләр үткәрү, ишегалдын эстетик бизәүдә иҗади инициатива күрсәтүдә халыкның катнашуы, шул исәптән чәчәк түтәлләре булу | |
| **9** | Кече архитектура формаларын карап тоту (эскәмияләр, балалар һәм спорт мәйданчыклары, чүп савытлары, кием киптерү, келәмнәр кагу өчен җайланмалар булу һәм аларның торышы) | |
| **10** | Контейнер мәйданчыгын карап тоту (тышкы кыяфәте һәм санитар торышы) | |
| **11** | Мәҗбүри мәгълүмат урнаштырылган белдерү тактасы (такталары), күрсәткечләр булу | |
| **12** | Ишегалды территориясенең яктыртылышы | |
| | **БАРЛЫГЫ:** | |

7 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2022 елның 16 маендагы 168
номерлы карары белән расланды

**2022 елда төзекләндерү буенча муниципаль конкурслар үткәрүнең конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Шакиров Әнәс Шәүкәт улы | Район Башлыгы урынбасары, комиссия рәисе; |
| Шәйдуллин Дамир Фәрит улы | Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия әгъзасы; |
| Сабирҗанов Ринат Рәшит улы | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, комиссия әгъзасы; |
| Булгаков Мурад Рамил улы | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, комиссия әгъзасы; |
| Хөснетдинов Артур Мифтахетдин улы | Төзелеш һәм ТКХ бүлеге башлыгы, комиссия әгъзасы; |
| Таҗиев Илдар Илгизәр улы | Биектау муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы, комиссия әгъзасы; |
| Кәримов Рәхимҗан Зариф улы | Татарстан Республикасының Биектау муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы, комиссия әгъзасы; |
| Сабирҗанов Марат Таһир улы | Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча район башлыгы ярдәмчесе, комиссия әгъзасы; |
| Касюков Муса Нигъмәт улы | Пенсионерларның җирле берлеге рәисе, комиссия әгъзасы; |
| Минһаҗев Раил Равил улы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Административ-техник инспекция» МКУ җитәкчесе, комиссия әгъзасы; |
| Мостафина Эльвира Әнвәр кызы | «Татмедиа» АҖ филиалы «Биектау хәбәрләре» район газетасы баш мөхәррире, комиссия әгъзасы |

8 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2022 елның 16 маендагы 168
номерлы карары белән расланды

**20__ елның «__» _______на(нә) чыгымнар буенча хисап**

Алучының исеме: ___________________
Вакыты: ______________________________
Үлчәү берәмлеге: ___________________________сум (икенче унарлы берәмлеккә кадәр төгәллек белән)

| | Сумма | | Чыгымнарны гамәлгә ашыруны раслаучы түләү документлары реквизитлары |
|---|---|---|---|
| | Хисап чоры | Ел башыннан бирле үсеп килүче нәтиҗә | |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Акча күчте, барлыгы: | | | |
| шул исәптән: Биектау муниципаль районы бюджетыннан | | | |
| Чыгымнар буенча түләүләр, барысы: | | | |
| шулардан: | | | |
| шул исәптән: | | | |
| максатчан булмаган билгеләнештә тотылган | | | |
| штраф санкцияләре куллану нәтиҗәсендә | | | |
| Хисап чоры ахырына трансферт калдыгы, барлыгы: | | | |
| шул исәптән: | | | |
| шул ук максатларга юнәлешкә кирәк | | | |
| кайтарылырга тиешле | | | |

Хисапка тиешенчә расланган түләү документларының күчермәләре кушып бирелә.

Башкаручы ____________ ___________________ ___________________
(вазыйфа) (Ф.И.А.)
телефон ____________________ «____»_________20____ел